ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ШУБАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ШУБАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«25» август 2025ел.

**КАРАР**
№78

**«Чүпне, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны һәм төрле эшләнмәләрне яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында» 17.12.2018 елгы 10 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге башкарма комитеты карарына (28.02.2023 елгы 31 номерлы редакциядә) үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законы, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 03.02.2025 ел, № 90 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шубан авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Чүпне, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны һәм төрле эшләнмәләрне яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында» 17.12.2018 елгы 10 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге башкарма комитеты карарына (2023 елның 28 февралендәге 31 номерлы редакциядә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «1.1. Торак пунктларның гомуми кулланылыштагы җирләрендә, шулай ук торак пунктлар территорияләрендә урнашкан хосусый йорт биләмәләрендә азык әзерләү өчен ачык ут куллану, шулай ук чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыкларны, махсус билгеләнгән һәм җиһазландырылган урыннан тыш материалларны яисә эшләнмәләрне яндыру тыела.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен кон ольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Шубан авыл җирлеге башлыгы С.З.Васильева